Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Манзарас авыл җирлеге Советы

# КАРАР

21 май 2024 ел №17

«Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» 2009 елның 06 июлендәге 17 номерлы Манзарас авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Манзарас авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» 2009 елның 06 июлендәге 17 номерлы Манзарас авыл җирлеге Советы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. преамбулада «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән дигән сүзләрне «Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы белән» дигән сүзләргә алмаштырырга;

1.2. карарның кушымтасында (Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәдә):

1.2.1. 1.2. пунктында «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән дигән сүзләрне «Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы белән» дигән сүзләргә алмаштырырга;

1.2.2. 2.2 пунктында «алуга, саклауга, тапшыруга һәм башка төрле куллануга» сүзләрен «эшкәртүгә» сүзләре белән алыштырырга;

1.2.3. 2.3 пунктында «(алу, саклау, комбинацияләү, тапшыру һәм башка куллану)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2.4. 2.5 пунктында:

б) 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;»;

4 пунктчасы «хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат» сүзләрен өстәргә;

6 нчы пунктчада «мәҗбүри пенсия иминияте иминият таныклыгы» сүзен «индивидуаль (персонификацияләнгән) исәп-хисап системасында теркәлүне раслаучы документ» сүзләре белән алыштырырга;

8 нче пунктчада «хәрби бурычлы» дигән сүзне «запаста булган гражданнар» дигән сүзләр белән алыштырырга;

9 нчы пунктчада «медицина учреждениесе» сүзен «медицина оешмасы» сүзләре белән алыштырырга.

түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктчасын өстәргә:

«10.1) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.1 статьясында каралган мәгълүматлар»;

1.2.5. 2.6 пунктда «Мәгълүматлар» сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.2.6. 7.3 пунктында.:

5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яки) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар, хәрби яки башка хезмәтне (булган очракта) үтүен раслаучы документ күчермәсе;»;

6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) белем һәм (яки) квалификация турында документлар, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирү турында документлар (әгәр алар булса) күчермәләре;»;

14 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

21 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21) шәхси (персонификацияләнгән) исәп-хисап системасында теркәлүне раслаучы документ күчермәсе;»;

1.2.7. 7.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 нче пунктны өстәргә:

"5) Россия Социаль фондының мәгълүмати ресурсларында саклау өчен, (дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан тыш), мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персонификацияләнгән) исәп-хисап турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт үткән чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат формалаштыруны һәм күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыруны тәэмин итү.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы урынбасары В.М.Ахатов